ГЛАВА ПОДЛЕСНО-ШЕНТАЛИНСКОГО СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ АЛЕКСЕЕВСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ АЛЕКСЕЕВСК МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫНЫҢ УРМАН АСТЫ ШОНТАЛАСЫ АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ БАШЛЫГЫ

Урман Асты Шонталасы ав.

ПОСТАНОВЛЕНИЕ

КАРАР

03.11.2021

№1

**«Гражданнарның үзара салым акчаларын кертү һәм куллану мәсьәләсе буенча Алексеевск муниципаль районының Урман Асты Шонталасыавыл җирлегенең Урман Асты Шонталасы авылында гражданнар җыенын билгеләү турында»**

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 06 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 56, 25.1 маддәсендәге 1 өлешенең 4, 4.1 һәм 4.3 пунктлары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 маддәсе, Алексеевск муниципаль районының Урман Асты Шонталасыавыл җирлеге Уставының 23 маддәсе, Татарстан Республикасы Алексеевск муниципаль районының Урман Асты Шонталасыавыл җирлеге Советының 2019 елның 08 октябрендәге 105 номерлы карары белән расланган Татарстан Республикасы Алексеевск муниципаль районы Урман Асты Шонталасыавыл җирлеге составына керүче торак пунктларда гражданнар җыенын әзерләү һәм уздыру тәртибе турындагы Нигезләмәнең 2.5 пункты нигезендә

**карар бирәм:**

1. Гражданнар җыенын оештыручы итеп Татарстан Республикасы Алексеевск муниципаль районының Урман Асты Шонталасы авыл җирлеге башлыгын билгеләргә.

2. Татарстан Республикасы Алексеевск муниципаль районы Урман Асты Шонталасыавыл җирлегенең Урман Асты Шонталасыавылында үзара салым акчаларын кертү һәм куллану мәсьәләсе буенча гражданнар җыенын 2021 елның 19 ноябренә 14:00 сәгатькә билгеләргә.

Җыенны үткәрү урыны итеп түбәндәге адрес буенча урнашкан АМЙ бинасын билгеләргә: Татарстан Республикасы, Алексеевск районы, Урман Асты Шонталасы ав, Г.Тукай ур., 42 й.

3. Гражданнар җыенына чыгарыла торган сорауны расларга:

«Урман Асты Шонталасыавыл җирлеге территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган кешедән 2022 елда үзара салым кертүгә сез, 1 нче төркем инвалидлардан, көндезге уку студентларыннан, Россия Армиясе

сафларына ашыгыч хезмәткә чакырылган гражданнардан тыш, 800 сум күләмендә һәм түбәндәге эшләрне башкару буенча җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә алынган акчаларны җибәрү белән килешәсезме:

- җирлек эчендәге юлларны карап тоту һәм ремонтлау;
-юлларны ремонтлау өчен вак таш сатып алу;
-бензогенераторны сатып алу;
- контейнерлар сатып алу;
- роторлы чапкычлы мотоблок сатып алу;
-тракторны карап тоту (тракторчыга түләү, ягулык-майлау материаллары сатып алу, запас частьләр сатып алу)
- су белән тәэмин итү челтәрләрен ремонтлау (материал сатып алу);
- карны чистарту;
-җирләү урыннарын төзекләндерү (материал сатып алу);
-Бөек Ватан сугышы һәйкәлен төзекләндерү;

ӘЙЕ ЮК».

4. Әлеге карарны Урман Асты Шонталасы авыл җирлегенең рәсми сайтында, хокукый мәгълүмат порталында, шулай ук Татарстан Республикасы Алексеевск муниципаль районының Урман Асты Шонталасы авыл Советы бинасында мәгълүмат стендында бастырып чыгарырга (халыкка җиткерергә).

5. Әлеге карар басылып чыккан көненнән үз көченә керә.

Урман Асты Шонталасы авыл җирлеге башлыгы А.Ә.Җиһаншин